**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**22.10.2013** **№ 01-02/130**

**“Татарстан Республикасы”, “Татарстан” атамаларын һәм алар нигезендә төзелгән сүзләрне һәм сүзтезмәләрне (шул исәптән кыскартылмаларны) юридик затлар исемнәрендә куллануга Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүләренең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2012 елның 14 июлендәге № 01-02/40боерыгы белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы нигезендә БОЕРЫК БИРӘМ:

1. “Татарстан Республикасы”, “Татарстан” атамаларын һәм алар нигезендә төзелгән сүзләрне һәм сүзтезмәләрне (шул исәптән кыскартылмаларны) юридик затлар исемнәрендә куллануга Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүләренең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2012 елның 14 июлендәге № 01-02/40 боерыгы белән расланган административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең 2.12 пунктындагы икенче баганaны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Чират булганда кәгазь чыганакта рөхсәт алуга гариза бирү - 15 минуттан артмаган вакытта.

Дәүләт хезмәт күрсәтүләре нәтиҗәсен алганда чираткөтүнең максималь срогы15 минуттан артмый.

Дәүләт хезмәт күрсәтүләрне алучыларның аерым категорияләре өчен чиратлылык билгеләнми.”;

3 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, өзлеклелеге һәм аларны башкару сроклары, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре”;

4 бүлекнең4.8. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәт күрсәтүләрен гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору Министрлыкка мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән, шулай ук Регламентны үтәү барышында башкарыла (кабул ителә) торган гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм карарларга дәүләт хакимиятенең югарыррак органына шикаять белдерү юлы белән гамәлгә ашырыла.”;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.8. пункт өстәргә:

“5.8. Шикаятьне карау барышында яисә шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яисә җинаять ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат кичекмәстән булган материалларны тиешле органнарга җибәрә.”.

2. Әлеге Боерыкны тикшереп торуны министрның беренче урынбасары С.Н.Столяровка йөкләргә.

Министр М.М. Корманов